# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тырыш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

23 ноябрь 2024 ел № 1

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 23 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Ирекле авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 300 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, Тырыш торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре, килешү буенча эш өчен түләү);
- Тырыш торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (вак ташны сатып алу, ташу, Октябрьнең 70 еллыгы урамына вак ташны җәю (эшкә килешү буенча түләү)).

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 42 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 23.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 23, «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүче юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә, **гражданнар җыены карар итте**:

1. Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Ирекле торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2025 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, мобилизацияләнгән, хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән һәм махсус хәрби операциягә җибәрелгән гаилә әгъзасы булган гаиләләрдән тыш, Азнакай муниципаль районы Илбәк авыл җирлеге Тырыш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә, 2 төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкән пенсионерлардан, күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр түләтүне 300 сумга киметеп, үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- торак пункт территориясен төзекләндерү (тракторчыга механикалаштырылган кар җыю буенча хезмәтләр өчен түләү, Тырыш торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмалар хезмәтләре, килешү буенча эш өчен түләү);
- Тырыш торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзекләндерү, ремонтлау, карап тоту (вак ташны сатып алу, ташу, Октябрьнең 70 еллыгы урамына вак ташны җәю (эшкә килешү буенча түләү))".

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Тырыш бистәсе, Октябрьнең 70 еллыгы урамы, 1 йорт; Илбәк авылы, Ә.Вәлиев урамы, 50 йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендынларында урнаштырырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Илбәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Илбәк авыл җирлеге башлыгы Р.К.Галимҗанова